СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2026 елның 29 мае № 9/14

Муниципаль мөлкәтне гавами тәкъдим юлы белән сатуны оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 августындагы 860 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 18 октябрендәге 1731 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Муниципаль мөлкәтне гавами тәкъдим ярдәмендә һәм бәя игълан итмичә сатуны оештыру турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2017 елның 15 декабрендәге 22/5 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәтне гавами тәкъдим юлы белән сатуны оештыру турындагы нигезләмәгә, **25 пунктка** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектын сату буенча конкурста җиңүчегә әлеге мөлкәтне сатып алу бәясеннән арткан суммада задатканың бер өлеше кире кайтарыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров